# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**“Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны торак урыннары белән тәэмин итү турында һәм “Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында” Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында” Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәреш кертү турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2013 елның 24 октябрендә
кабул ителде

**1 статья**

“Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны торак урыннары белән тәэмин итү турында һәм “Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында” Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында” 2013 елның 12 гыйнварындагы 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 5 өлешенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 1), аңа түбәндәге эчтәлекле абзац өстәп, үзгәреш кертергә:

“Вәкаләтле орган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары буенча һәм “Татарстан Республикасында торак төзелеше үсешенә дәүләт ярдәме турында” 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыручы махсуслаштырылган оешма (коммерциячел булмаган республика оешмасы) белән килешү нигезендә соңгысына вәкаләтле орган исеменнән ятим балаларга торак урыннарын фактта бирү һәм алар белән югарыда күрсәтелгән шартнамәләр төзү гамәлләрен башкаруны йөкләргә мөмкин.”.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ
БҮЛЕК
ОБЩИЙ
ОТДЕЛ

Казан,Кремль
2013 елның 28 октябре
№ 84-ТРЗ